## Инспектор аңлата:

### Соңгы тикшерү ничек һәм кайда үткәрелә?

07.10.2015

**Җавап:**

Инспекция тарафыннан капиталь төзелеш объектының ***төзелеше, үзгәртеп корылышы тәмамлану турында*** төзүчедән (техник заказчыдан) хәбәр алынгач (“Инспектор аңлата” материалларының элеккеге чыгарылышларын карагыз) объектта күзәтчелек башкару өчен җаваплы булган вазифаи зат 7 эш көне дәвамында төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив-хокукый актларның һәм проект документларының таләпләренә ярашуын карау буенча соңгы тикшерү (алга таба – соңгы тикшерү) оештыра (билгели) һәм “хокук бозулар ачыкланган очракта тиешле административ чаралар күреп тикшерүләр үткәрү” административ процедурасы нигезендә тикшерү үткәрә.

Вазифаи затлар ***соңгы тикшерүне*** үткәрә, техник регламентлар (нормалар һәм кагыйдәләр), башка норматив-хокукый актлар, проект документлары буенча ачыкланган бозу очракларына карата, ***соңгы тикшерү актына*** теркәп, үз имзаларын куеп, кисәтүләрен җиткерә.

***Соңгы тикшерү акты*** соңгы тикшерүне үткәргән вазифаи затлар тарафыннан ике нөсхәдә әзерләнә һәм имзалана (бер нөсхәсе төзүчегә (техник заказчыга) бирелә, икенчесе дәүләт төзелеш күзәтчелеге органында кала).

***Кисәтүләрне*** (булган очракта) һәм ***бозуларны бетерү турында күрсәтмәсе булган соңгы тикшерү акты*** объектта күзәтчелек башкару өчен җаваплы булган вазифаи зат тарафыннан төзүчегә (техник заказчыга) җибәрелә.

***Соңгы тикшерү актын*** алганнан соң һәм ***кисәтүләрне бетергәннән*** соң төзүче (техник заказчы) Инспекциягә ачыкланган бозуларны бетерү турында хәбәрнамә, капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы тәмамлану турында хәбәрнамә җибәрә.

***Соңгы тикшерү акты*** (кисәтүләре булмаган) төзүчегә (техник заказчыга) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив-хокукый актларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән энергетика ягыннан нәтиҗәлелек таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителешенә карата булган таләпләргә ***ярашуы турында бәяләмә*** (алга таба – ЯТБ) алу өчен нигез булып тора.

***Кисәтүләре булган соңгы тикшерү акты***, төзүче яки техник заказчы ЯТБ бирүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, ***ЯТБ бирүдән баш тарту*** турында карар кабул итү өчен нигез булып тора.

*ТР ДТКИ матбугат хезмәте*